**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«20» 11 2019 ел №511911

2019 елда Тукай муниципаль районында кимендә өч савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сатып алынган саву аппаратларына чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, шулай ук шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү, авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру өчен уңай шартлар тудыру максатында, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2019 елда Тукай муниципаль районында кимендә өч савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сатып алынган саву аппаратларына чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен (алга таба – тәртип) 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. 2019 елда Тукай муниципаль районында кимендә өч савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сатып алынган саву аппаратларына чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирүгә гаризаларны карау буенча конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен кнтрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең икътисад һәм эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү буенча беренче урынбасары А.Р. Хәбибуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның ___11___ номерлы карарына 1 кушымта

2019 елда Тукай муниципаль районында кимендә өч савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сатып алынган саву аппаратларына чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе

1. Субсидия алу хокукына ия булган шәхси ярдәмче хуҗалыклар категорияләре һәм сайлап алу критерийлары

1.1. Шәхси ярдәмче хуҗалык – авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү буенча эшмәкәрлек булмаган эшчәнлек формасы. Шәхси ярдәмче хуҗалык гражданин яки аның белән бергә яшәүче һәм (яки) аның белән бергә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруны гамәлгә ашыручы аның гаилә әгъзалары белән берлектә гражданин тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән һәм (яки) сатып алынган җир кишәрлегендә шәхси ихтыяҗны канәгатьләндерү максатында алып барыла.

1.2. Сатып алынган саву аппаратларына чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр (алга таба – субсидияләр) Тукай муниципаль районы составына керүче торак пунктларда теркәлгән һәм Тукай муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга үз милкендә кимендә өч савым сыеры булганда бирелә.

1.3. Субсидияләр гариза нигезендә бирелә.

2. Субсидияләр бирүнең максатлары, шартлары һәм тәртибе

2.1. Субсидияләр бирүнең максаты – авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү буенча савым сыерларының баш санын саклап калуны һәм терлекчелек продукциясен җитештерүне тәэмин итү, гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыкларында савым сыерларының баш санын арттыруны стимуллаштыру.

2.2. Субсидияләр шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу буенча хуҗалык кенәгәсеннән өземтә нигезендә, субсидия алуга гариза белән мөрәҗәгать итү датасы торышы буенча, сатып алынган саву аппараты бәясенең 60% ы күләмендә, ләкин бер шәхси ярдәмче хуҗалыкка 18000 сумнан артмаган күләмдә бер елга һәм кимендә өч савым сыеры исәбеннән бер савым аппаратына бирелә.

Субсидияләр Тукай муниципаль районы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче, шәхси ярдәмче хуҗалыкта кимендә өч сыер асраучы гражданнарга бирелә. Берничә кандидат булса, өстенлек терлекләрнең баш саны буенча һәм аларны карап тоту срогы зуррак булганга бирелә.

Шәхси ярдәмче хуҗалыкта савым сыерларының баш саны 2019 елның 1 гыйнваре дәрәҗәсеннән кимегәндә, субсидияләр бирелми.

2.3. Субсидия алу өчен, гражданнар Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитет) түбәндәгеләрне тапшыралар:

- субсидияләр бирү турында гариза һәм әлеге тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә йөкләмә;
- сату-алу (китереп бирү) килешүе күчермәсе;
- сатып алынган саву аппараты бәясен раслаучы түләү документлары (квитанция, касса чегы яки банк өземтәсе һәм түләү поручениесе);
- гариза бирүченең паспорт күчермәсе;
- банк реквизитлары (гариза бирүченең саклык кенәгәсе күчермәсе).

2.4. Гариза теркәлгәннән соң, 3 эш көне эчендә Башкарма комитет конкурс комиссиясен чакыра, ул:

- кергән гаризаларны карый, документлардагы мәгълүматларның дөреслеген тикшерә;
- бирелгән документлар нигезендә субсидияләр бирүгә белешмә-расчетлар төзи;
- субсидия бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында беркетмә формасында карар чыгара.

Башкарма комитет конкурс комиссиясе карар кабул иткән мизгелдән соң 3 эш көне эчендә субсидия алучыга кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Субсидия бирү турында карар кабул иткәндә, беркетмә Башкарма комитетның хисап һәм хисаплылык бүлегенә җибәрелә.

2.5. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез:

субсидия алучы тапшырган документларның әлеге пунктның 2.2 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки 2.3 пунктта күрсәтелгән документларны тапшырмавы (тулы күләмдә тапшырмавы);

субсидия алучы тапшырган мәгълүматның дөрес булмавы.

2.6. Конкурс комиссиясе беркетмәсе нигезендә Башкарма комитет субсидия бүлеп бирү турында карар кабул итә.

2.7. Субсидияне күчерү Башкарма комитетның хисап һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан, унынчы эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия алучының банкта ачылган исәп-хисап счетына Тукай муниципаль районы бюджетында әлеге максатларга каралган акчалар чикләрендә да башкарыла.

2.8. Мөрәҗәгать итүче гражданнар субсидия бирүдән баш тарту турында карарларга гамәлдәге законнар нигезендә шикаять бирү хокукына ия.

Приложение №1 к Порядку

Руководителю
Исполнительного комитета
Тукаевского муниципального района
___________________________________
от_________________________________
___________________________________
___________________________________
(Ф.И.О., адрес проживания)

Заявление

о предоставлении субсидии на возмещение части затрат за приобретенные доильные аппараты личным подсобным хозяйствам, имеющим не менее трех дойных коров в 2019 году

Я, __________________________________________________________________________,
(Фамилия, Имя, Отчество)

Паспорт серия _______, №_____________, выдан ___________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________,
проживающий(ая) по адресу: _____________________________________________
_____________________________________________________________________________
телефон_____________________________, ИНН ____________________________,
прошу Вас выделить мне причитающуюся субсидию на возмещение части затрат за приобретенные доильные аппараты личным подсобным хозяйствам, имеющим не менее трех дойных коров в 2019 году, содержащихся в моем личном подсобном хозяйстве (далее по тексту - субсидия). Сообщаю, что количество дойных коров на личном подворье, расположенное по адресу: Республика Татарстан, Тукаевский район, _________________________________________
_________________________________по состоянию на _______________20___г. составляет _________( _______________ ) голов.

С условиями участия в Порядке предоставления субсидии ознакомлен(а) и согласен(а).

В случае предоставлении субсидии, обязуюсь: не уменьшать поголовье дойных коров в течение трех лет после получении субсидии, предоставлять отчетность в запрашиваемые сроки и использовать субсидию по целевому назначению.

Вся информация, содержащаяся в представленных документах или их копиях, является подлинной, и не возражаю против доступа к ней лиц, участвующих в рассмотрении документов на предоставление субсидии.

_______________/___________________________/ « ___ » __________ 20____г.
(подпись) (Ф.И.О.)

Обязательство
о целевом использовании субсидии гражданином,
ведущим личное подсобное хозяйство и имеющим не менее трех дойных коров
на приобретение доильных аппаратов в 2019 году

Я, ________________________________________________________________________,
Паспорт серия ________, №___________________, выдан______________________
________________________________________________________________________,
проживающий(ая) по адресу: _______________________________________________
__________________________________, ИНН____________________ , обязуюсь:

1. Использовать субсидии, полученные на возмещение части затрат за приобретенные доильные аппараты личным подсобным хозяйствам, имеющим не менее трех дойных коров в 2019 году (далее - субсидии) в соответствии с постановлением Исполнительного комитета Тукаевского муниципального района от «____» ______________20___г. №________ «Об утверждении порядка предоставления субсидий на возмещение части затрат за приобретенные доильные аппараты личным подсобным хозяйствам, имеющим не менее трех дойных коров в 2019 году в Тукаевском муниципальном районе» строго по целевому назначению на содержание дойных коров в своем личном подсобном хозяйстве, расположенного по адресу: ___________________________________
______________________________________________________________________.

2. Предоставить беспрепятственный доступ членам Конкурсной комиссии в личное подсобное хозяйство для проверки целевого использования полученных субсидий, представлять необходимую информацию об использовании субсидии.

3. Осуществлять хозяйственную деятельность по содержанию дойных коров, не уменьшать имеющееся поголовье дойных коров, согласно заявленной при получении субсидии, в течение не менее 3 календарных лет с момента получения субсидии.

4. В случае невыполнения пунктов 1-3 обязательства - вернуть полученную сумму субсидии в бюджет Тукаевского муниципального района в течение 60 дней с даты составления акта нецелевого использования полученной субсидии и несоблюдения условий подписанного обязательства.

Любые изменения и дополнения к настоящему обязательству действительны лишь при условии, если они совершены в письменной форме и подписаны Сторонами. Во всем ином, не урегулированном в настоящем обязательстве, будут применяться нормы действующего законодательства Российской Федерации и Республики Татарстан. При подписании настоящего обязательства стороны констатируют об отсутствии в нем неясности понятий и определений.

Я,_____________________________________________, в соответствии с Федеральным законом от 27.07.2006г. №152-ФЗ «О персональных данных», выражаю свое согласие на обработку информации, относящейся к персональным данным, которые предоставлены при заключении и исполнении данного обязательства. Данное согласие предоставляется на весь срок действия заключенного обязательства (3 года с момента подписания).

______________/___________________________/ « ___ » __________ 20____г.
(подпись) (Ф.И.О.)

Приложение №2 к  Порядку

Справка-расчет
о предоставления субсидий на возмещение части затрат
за приобретенные доильные аппараты личным подсобным хозяйствам,
имеющим не менее трех дойных коров в 2019 году
по  Тукаевскому муниципальному району

| № п/п | ФИО владельца ЛПХ | Место проживания | Паспортные данные | Поголовье дойных коров на «___»________ 20___г. | Ставка субсидии на одно личное подсобное хозяйство, % | Итого субсидий, рублей |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Достоверность сведений подтверждаю:

_______________________/ ______________________________/
(Ф.И.О.)                    (подпись)

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 20 11 5119/1 номерлы карарына 2 кушымта

2019 елда Тукай муниципаль районында кимендә өч савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сатып алынган саву аппаратларына чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирүгә гаризаларны карау буенча конкурс конкурс комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Хәбибуллин А.Р. | Башкарма комитет Җитәкчесенең икътисад һәм эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү буенча беренче урынбасары, конкурс комиссиясе рәисе |
| Шәмгунов И.В. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты икътисад бүлегенең әйдәп баручы белгече, конкурс комиссиясе секретаре |

Конкурс комиссиясе әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Бузина Н.К. | Тукай муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы |
| Вәгыйзова А.Р. | Тукай муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең терлекчелек буенча консультанты |
| Дудникова Е.А. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге җитәкчесе |
| Халитова Э.А. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының хисап һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| Хуҗагалиева Л.Н. | Тукай муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе. |